МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

29 апрель 2019 ел

№ М 171

Шәһәр Хакименең «Чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 маддәләрендә күздә тотылган җәзаларны куллану турында» 2012 елның 16 апрелендәге 242 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законнар нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 маддәләрендә күздә тотылган җәзаларны куллану турында» 2012 елның 16 апрелендәге 242 нче карары кушымтасының 7 пунктына, түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктча белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«2.1) хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупцион хокук бозуны кылуның факттагы шартлары бәян ителгән коррупцион хокук бозуларны кылу турында доклады һәм бары тик муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы һәм коррупцион хокук бозу фактын тану шарты белән аның язмача аңлатмасы (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә җәза кулланудан тыш);».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма

комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы Ф.И. Андреева